| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

ИНН 1627001291 ОГРН 1021601117592
423646 д. Псеево, ул. Центральная, д.4 Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru

18.06.2026 № 26

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә
муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль
хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары
турында нигезләмәне раслау хакында " 2023 елның
15 февралендәге 74 нче номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында "2023 елның 15 февралендәге 74 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 13 нче кушымтасында 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
“Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлары өчен” Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге медален алган өчен ай саен вазыйфаи окладның 5 проценты күләмендә өстәмә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: www.mendeleevsk.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар үз көчен 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә.

Песәй авыл җирлеге Советы рәисе В.И. Мөхәммәтгалеев